Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

31 октябрь, 2022 ел № 24

«16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентны раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 07 июнендәге 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 26 мартындагы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләр турында» 236 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 07 июнендәге 11 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризаның электрон формасы кырларының һәркайсын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон рәвештәге гариза бирүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән турыдан-туры гаризаның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Бањауов